«Катнаш төрдәге Балтач 4 нче балалар бакчасы”
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

Балаларны татар халкынын гореф гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре үрнәгендә тәрбияләү.

Балаларны татар халкынын гореф гадэтлэренә ойрәту хэм шушы гореф гадэтлэр аша гаилэдэ тэрбиялелек булдыру

Туган тел! Һәркем өчен газиз сүз бу. Чөнки тел – тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Тел ул зур бер гөлбакча кебек анда йөргән саен гөлләрнең төрлелегенә шаккатасың, хуш исләрең тоясың, матурлыгына сокланасың.

Тел кешеләргә бер-берсен аңларга, теләк-максатларын, уй-фикерләрен белергә ярдәм итә.

Бүгенге көндә балалар бакчасы тәрбиячеләре алдында торган бурычларның иң мөһиме – сабыйларга максатлы рәвештә – үз туган телен өйрәтү, шулай ук аларны халкыбызның сәнгате, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары , милли әдәбияты белән таныштыру.

Балаларга ана телен өйрәтүдә төп бурычларның берсе – халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф гадәтләренә таяну. Үз телен яратучы, милләт ен хөрмәтләүче кешене тәрбияләүне халык педагогикасына таянып эш итү зарур. Җор телле халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, санамышлар, такмаклар, әкиятләр, бәетләр, моңлы бишек җырлары – тел өйрәнүдә иң бай чыганак.

Татар халкының меңелларга сузылган тормыш тәҗрибәсе, уйлары, гадәтләре, кешене шәхси итүче сыйфатлары, аның телендә образлы сөйләмнәрендә, мәкаль-әйтемнәрендә, җыр һәм әкиятләрендә чагылыш тапкан. Шуңа күрә ата-анасы татар булган балага татарча белү, уку мәҗбүри итеп каралырга тиеш.

Сабый туганда шундый саф була. Ата-анасына, милләтенә, иленә таяныч булып үссен өчен, дөньяга килү белән аны тәрбияләү, мөмкинлегенә күрә акылын, зиһенен үстерү башлана.

Борын-борыннан ук билгеле: тәрбия, бала тугач та башлана һәм баланың киләчәктә үз-үзен тотышындагы, яшәвендәге кыенлыклар, көйсезлекләр, тискәрлек, үзсүзлелек, елаклык, сүзкитермәү, сүзендә тормау – начар тәрбия нәтиҗәсе.

Баланы беренче көненнән үк туплый башлаган хәзинәсе – туган теле. Ана сөте белән кергән туган тел сабыйда газиз анасына, әтисенә, әби-бабасына, туганнарына, туган туфрагына, чишмә һәм урманнарына, тереклек дөньясына мәхәббәт, аны белергә, төшенергә омтылу хисләредә тәрбияли.

Балага туган телне яхшы камилләштерүченең беренче чарасы булып уеннар тора. Уен – нәни шәхеснең әдәплелекнең төп кагыйдәләренә өйрәнүдә

безнең иң турылыклы, ышанычлы ярдәмебез. Чөнки алар – бала тормышының аерылгысыз өлеше. Уенна р тәрбия чыганагы буларак, баланың төрле яктан үсүенә йогынты ясый. Аларда катнашу сабыйның аңын, физик көче, җыр-биюгә осталыгын, сүзбайлыгын арттырырга ярдәмитә. Күмәкэшләү, ярдәмләшү, шәфкатьлелек, кушканны үтәү кебек уңай сыйфатларны үстерер.

Татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре, традицияләре, көнкүреш һәм тел үзенчәлекләре халык уеннарында киң чагылыш таба. Татар халкының уеннарын балалар бик тиз өйрәнәләр һәм бик теләп уйныйлар. Балаларга уен тәкъдим иткәндә, аларның иң яхшы үзләштерә торганнарын сайларга кирәк.

Башта сайлап алабыз, балалар түгәрәккә тезелеп баса да, шуннан соң санамыш үткәрәбез. Бер бала да рәнҗерлек булмасын өчен санамыш үткәрәбез.

Мәсәлән: Әке, бәке, ыскылагансәке

Карга, чыпчык, син кал, бучык.

Балаларның яшь зурлыгына туры китереп санамышлар куллану мөмкин.

Безнең күбрәк уйнаган уеннарыбыз "Мәче һәм тычкан", "Ябалак", "Йоклаган песи", "Очты, очты...", "Аю-бүре", "Күрсәт әле үскәнем". Уеннардан балалар уңай тәэсир алалар, шулай ук тел байлыгын арттыралар.

Төркемдә балалар белән "Серлекаҗчык", "Әбием сандыгы", "Танып бел", "Мәликә" кебек уеннар алына.

Сюжетлы-рольле уеннарга да бик зур урын бирелә. Бу балаларга бер-берсенә хөрмәт, әдәплелек хисен үстерергә ярдәм итә. Шулай ук дидактик уеннарга да зур урын бирелә. Бу уеннар "Нәрсә артык?", "Парын тап", "Кем баласы", "Калфак бизәү, комзол бизәү" һ. б. баланың дөрес фикерләү, уйлап табу сәләтен үстерә. Шөгыльләрне уздырганда физминутҡалар өчен кызыклы, хәрәкәтле күнекмәләр алабыз. Бу "Кәҗәмәкәрҗә" – уртәвеч, "Үчти-үчти, үчтеки", "Әти биштә". Балалар бик теләп катнашалар, үртәвечләрне бик тиз отып алалар.
Балаларда әдәплелек, әхлаки яктан камил булып үсеннәр өчен бик еш төрле әңгәмәләр үткәрәбез, мәсәлән, "Без кунакта", "Безнең гаилә", "Матур сүз әйт" һ. б.

Шулай ук сабыйлар өчен төрле альбомнар әзерлибез. Бу "Милли бәйрәмнәр", "Серле сандык" – анда халкыбызның милли киемнәре, бизәнү әйберләре, сөлгеләр, ашъяулыклар, тарихи булган урыннар сүрәте, туган якка багышланган альбомнарыбыз да бар.

Ел да балалар белән милли бәйрәмнәр үткәрәбез: “Сабантуй”, “Карга боткасы”, “Сөмбелә бәйрәме”, “Яңгыр боткасы” – балалар өчен күңелле вакыйга һәм ул гомерлеккә хәтер сандыгында саклана.

Балаларны сатира, юмор, үртәвечләр, үчекләүләр белән таныштыру аларның сөйләм телен үстерә, җор телле, тапкыр сүзле булырга да өйрәтә. Шуңа күрә өйдәдә балалар белән күбрәк ана телендә аралашырга, ана теленә мәхәббәт, ихтирам, соклану хисен тәрбияләү. Ә алдагы тормышта бу бирдәм хезмәт үзенең нәтиҗәсен безнең йөрәкләргә татлы җимеш итеп җиткерер.

Уеннар аркылы балаларга милли йолаларыбызны, бәйрәмнәребезне, такмаклар, табышмаклар, үртәвечләр белән барып ирештерсәк, безнең гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр онытылмас, гасырлардан-гасырларга күчеп дәвам итәр, мәңге сакланыр, милләтебез исән булыр.